| ГЛАВА<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2021 с.Старое Дрожжаное № 41

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 27 маендагы 9/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш, хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына кеше хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын билгеләргә - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән башлап. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы кимендә бер һәм өч айдан артык була алмый.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итәргә;

3.2 Әлеге Карарның үз көченә керү датасыннан әлеге Карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы билгеләгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең Генераль планы проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә җибәрергә.

4. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга https://droganoye.tatarstan.ru/ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләнә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы А.Е. Ярухин